Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы

Яңа Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

№ 8 18.09.2018 ел

**Референдум үткәрү инициативасы турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьяларына, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясына ярашлы 24.04.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында», Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Яңа Ибрай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге башкарма комитеты карары:

1.Җирле референдум үткәрү инициативасы:

"Сез 2019 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә урнашкан барлык гражданнар, шулай ук теркәлмәгән, әмма җирле референдумда катнашуларына һәм тавыш бирүдә белдергән мөнәсәбәтләренә карамастан, Яңа Ибрай авыл җирлеге территориясендә яшәүче яки милекләре булган һәр кешедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә, (1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар тыш), алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1. Торак пунктларда җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге.

Яңа Ибрай авылына юллар салу өчен вак таш сатып алу;

Яңа Ибрай авылына юлларны тигезләү;

- Кышкы юлларны тоту;

2. Торак пункт территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешен контрольдә тоту, күрсәтелгән Кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру.

яңа Ибрай авылында электр яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру;

ӨЙЕ ЮК

2.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://aksubaevo.tatar.ru Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Яңа Ибрай авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: Ф.Х.Кәбиров